**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 99-12 «14» декабрь 2021 ел

Азнакай муниципаль районы Советының 2018 елның 22 августындагы 203-30 номерлы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында» карары белән расланган, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (12.03.2020 №326-45, 16.04.2021 №46-7, 26.08.2021 №72-9 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатыннан,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1. Азнакай муниципаль районы Советының 2018 елның 22 августындагы 203-30 номерлы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында» карары белән расланган, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә (12.03.2020 №326-45, 16.04.2021 №46-7, 26.08.2021 №72-9 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 статьяның 2 һәм 3 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлекләрнең генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча (әлеге статьяда алга таба - иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар) иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар, әлеге статьяның 2.1 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында уздырыла.

2.1. Җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертелгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.

3. Иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлауларда катнашучыларны җәмәгать фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда катнашу өчен тигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатларында җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәргәндә торак пункт территориясе өлешләргә бүленергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында " түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин